ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

20.10.2020　　　　с. Русское Макулово　　　　04

Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Сеитово авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Сеитово авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 5 ноябренә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021нче елда Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Сеитово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булмаган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Сеитово авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү

«ӘЙЕ»　　　　　　　　«ЮК»

3. Халык җыенын Сеитово авылы, Центральная урамы, 6нчы йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасында үткәрергә.

4. Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы

Макыл авыл җирлеге башлыгы А. И. Матвеева